
# Яңа ел белән, дуслар!

Котлап бөтен кешеләрне
Яңа ел белән,
Җилдереп кенә пар атта,
Кыш бабай килә.




**Кадерле дуслар, укытучылар, әти-әниләр!**

Барыгызны да якынлашып килүче яңа ел белән котлыйбыз!

Бәйрәм- мөбарәк, ризык тулы өстәл- түгәрәк, күңелле, куанычлы булсын. Эшләрегез уң булсын, чәчәк атсын, күңелегездәге мәрхәмәтлелек нуры җаныгызны тагын да ягымлы, матур итсен, ялкынландырып бизәсен. Бусагаларыгыздан караңгылык, салкынлык, хәвеф - хәтәр атлап кермәсен, бәла - каза йөрмәсен. Гаилә бәхетегез сүнмәсен.

**Жарова Елизавета, 5нче сыйныф**

Яңа ел белән котлыйм,
Һәм чын күңелдән телим
Бәхет, шатлык, мәхәббәт
Телим бәйрәмдә һәркемгә
Шат күңелле булырга

**Макарова Ксения, 6нчы сыйныф**

Кыш житте, кыш житте,
Ә аның белән- бәйрәм!
Яңа ел, Яңа ел-
Бүләк алып киләчәк,
Бәхет һәм шатлык белән
Тантана башланачак.

**Емельянова Диана, 6нчы сыйныф**

Яңа елны каршылыйбыз
Шатланабыз, көләбез.
Зур бүләкләр, теләкләр
Кыш бабайдан көтәбез.

**Игнатова Анастасия, 6нчы сыйныф**

Яңа ел- күңелле бәйрәм,
Бар да жырлый һәм бии.
Бу бит гаилә бәйрәме
Хуш киләсең, Яңа ел!

**Колесова Владилена, 6нчы сыйныф**

Яңа ел- яраткан вакыт.
Мин күңелле ел телим.
Яңа ел ап-ак була,
Алып килә барсына
Күп бәхет һәм шатлыклар.

**Кудряшова Арина, Муллахметова Алия, 7 нче сыйныф**

Каршы алабыз бәйрәмне,
Әкияткә бергә эләгәбез.
Анда алабыз бүләкне,
Кыш бабайны күрәбез.
Илдә тылсым башлана,
Яңа ел килә монда.
Күп уңайлыклар туа,
Һәм чыршы белән арта.



Гильфанова Лилия, 4нче сыйныф

**Шәймөхәммәтов Адель, 7 нче сыйныф**

Басып тора минем алда
Яшел матур чыршы-бала.
Астында бүләкләр ята
Балалар Кыш бабайны ярата.

**Ханова Алсу, 8нче чыйныф**

***

Ноябрьнең, ягъни, көз аеның соңгы көннәре.Кышны көтәбез, аклык көтәбез, сафлык көтәбез.Ә ак карның әсәре дә күренми, әйтерсең, быел кыш бөтенләй килмәс кебек.

Без бүген авылда, ялга кайттык. Авылымны горур таулар уратып алган.Татар Мөшегесе дип атала безнең авыл. Аның биек- биек тауларында без кышкы каникулларда чана шуарга яратабыз. Гаиләбез белән- этием, әнием, сеңлем һәм мин- Алсу.Тауның иң биек җиреннән, бабайдан калган зур чанага төялеп, шуарга яратабыз. Кайчагында, мәтәлеп китеп, як-якка чәчеләбез. Рәхәтләнеп ап-ак карда ауныйбыз.Гүя без кышның аклыгын, сафлыгын үзебезгә җыябыз.Әйтерсең, без күңелләребезне шушы аклык белән чистартабыз.Безгә бик рәхәт.

Мин шулай кышны сагынып, тәрәзәгә күз салдым. Тау башлары әле кызыл. Ирексездән:
Кызыл әле таулар,
Ямый әле карлар.
“Ходай үзе белер әле!”-дип көндәлек дәфтәремә язып куйдым.

Ә иртән мине сеңлем Адилә уятты. “Апам, тиз бул, тәрәзәгә кара”,- диде ул миңа бик шатланып. Мин ашыгып тәрәзәгә күз салдым. Тышта ап-ак кыш иде...

**Гайнетдинова Ильвина, 4 нче сыйныф**

***

Кыш көне урамда бик салкын.Бөтен агачлар, куаклар ап-ак шәл белән бөтерелгән.Җир ап=ак юрган астында тыныч кына ял итә.

Балалар бик җылы киенгәннәр. Алар кар бабай һәм Кар кызын ясарга яраталар.

Мин кыш көне чана- чаңгыда шуам.Кышын урамда бик күңелле.

Минем яраткан бәйрәмем- Яңа ел була.Кыш бабай бик күп бүләкләр алып килә. Ап-ак карлары, салкыннары, бәйрәмнәре белән миңа кыш бик ошый.



Хабибуллина Алия, 2нче сыйныф

**Җәләева Азалия, 3нче сыйныф**

Кыш,кыш, кыш дибез,
Ак карны без күрмибез.
Декабрь башланса да,
Сапоги белән йөрибез.
Яңа ел бәйрәмнәрендә
Тау шуасы урында
Чатыр тотып үтәр инде
Җылы яңгыр астында.



Никитина Арина, 2нче сыйныф

**Буяп карагыз!**




Ваганова Валерия, 7нче сыйныф



Гайнетдинова Ильвина, 4нче сыйныф

**Багаутдинова Алина, 9нчы сыйныф**

Яңа ел килгән,
Бәйрәм башланган.
Кыш бабай безгә килә
Һәм бүләкләрен бирә.



Айзилә, 2нче сыйныф


**Сафиуллина Алина, 8нче сыйныф**

Ап-ак кыш килде,
Җирне юрган каплады.
Вакыт тукталды,
Тирән йокыга талды.
Ә балалар бик шат
Чана, чаңгы алды
Һәм бәйрәмне көтте.



**Петрова Анастасия, Бурганова Рената, 5нче сыйныф**

Исәнме, Яңа ел!
Сорыйм мин синнән
Бик күп бүләкләр.
Ә Кыш бабай безгә
Яхшы бүләк әзерлә.



Притчина Анастасия, 7нче сыйныф



Галимарданова Карина, 2нче сыйныф



Ильясова Карина, 2 нче сыйныф



Низамов Камил, 2нче сыйныф



Минеев Равиль, 4 нче сыйныф

**Круглов Данил, 8 нче сыйныф**

Минем әтием, минем әнием,
Бүген Яңа ел, бүген яхшы көн!
Көткән бүләкләр, күңелле җырлар,
Монда Кыш бабай һәм күп кунаклар.
Ә чыршы матур, йолдызы бик зур.
Яхшы бәйрәмне яратам бит мин.


РЕБУСЛАРНЫ ЧИШЕГЕЗ:




Нуриева Алина, 4нче сыйныф




Новикова Ксения, 4нче сыйныф




Вафина Виктория, 4нче сыйныф

**Саидов Нариман, 6нчы сыйныф**

Менә Яңа ел килде. Урамда балалар уйныйлар. Алар шатланалар. Миңа әтием әфлисуннар алып кайта. Ә мин әни белән чыршы бизим. Мин Яңа елны бик яратам!



Валиев Ренат, 4 нче сыйныф

**Симонов Ринат, 9нчы сыйныф**

Тиз-тиз безгә килә
Әкиятче Яңа ел.
Булмаса да эш җиңел-
Ясыйбыз кар бабае.
Кар бабай әзер "Урраа!"
Матур чыршы утыра,
Килеп җитә Кыш бабай
Һәм бүләкләр тарата.

**Минеев Равил, 4нче сыйныф**

***

Кыш житте. Урамда ап-ак кар ява.Балалар кар бабай ясыйлар. Мин кардан кечкенә шар ясыйм. Ә дусларым чана, чаңгы, тимераякта шуалар. Бигрәк рәхәт кыш көне!Шуңа да мин кышны яратам.



Перевалов Арсений, 7нче сыйныф

**Потапова Вероника, 4нче сыйныф**
**Табышмак.**

Тора ул 3 шардан,
һәм тагы кардан.
Күзе кумердән,
борыны кишердән.